**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2074**
**01.04.2024**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен түбәндәге аралыкта билгеләргә:

1) белем бирү оешмалары милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, бүлмәләрдән (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) – 25 метр;

2) балигъ булмаганнарны укытуны гамәлгә ашыра торган оешмалар милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, бүлмәләрдән – 25 метр;

3) оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм төп (устав) эшчәнлек төре сыйфатында медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган яки төп (устав) эшчәнлеге белән беррәттән Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш,

медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган шәхси эшмәкәрләр милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, бүлмәләрдән – 30 метр;

4) вокзаллардан – 30 метр;

5) күчемсез милек объекты булган һәм аңа хокуклар тиешле тәртиптә теркәлгән спорт корылмаларыннан – 30 метр;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган аеруча куркыныч чыганаклар урнашкан урыннан – 50 метр.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлардан алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләренә кадәр араны әлеге карарга кушымтада каралган тәртиптә билгенәнүне билгеләргә.

3. Башкарма комитетның «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» 2013 елның 20 маендагы 3136 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 1 апрелендәге
2074 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре
күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган
янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү
тәртибе

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләре түбәндәгечә билгеләнә:

1) аерым территория (чикләре койма белән (ясалма объектлар белән) тотып алынган территория) булганда – килүчеләр өчен:

- белем бирү оешмалары милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, бүлмәләрнең (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш);

- балигъ булмаганнарны укытуны гамәлгә ашыра торган оешмалар милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, бүлмәләрнең;

- оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм төп (устав) эшчәнлек төре сыйфатында медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган яки төп (устав) эшчәнлеге белән беррәттән Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган шәхси эшмәкәрләр милкендәге һәм (яки) файдалануындагы биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, бүлмәләрнең;

- вокзалның;

- күчемсез милек объекты булган һәм аңа хокуклар тиешле тәртиптә теркәлгән спорт корылмаларының;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган аеруча куркыныч чыганаклар урнашкан урынның

аерым территориясенә керү урыныннан килүчеләр өчен стационар сәүдә объектына һәм (яки) җәмәгать туклануы объектына керү урынына кадәр;

2) аерым территория булмаганда – килүчеләр өчен әлеге тәртипнең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән объектлар бинасының (төзелмәсенең, корылмасының) керү урыныннан килүчеләр өчен стационар сәүдә объекты һәм (яки) җәмәгать туклануы объектына керү урынына кадәр.

2. Әлеге тәртипнең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән объектлардан янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара тротуарлар яки җәяүлеләр юллары (алар булмаганда – юл читләре, велосипед юллары, машина юлларының читләре буйлап), җәяүлеләр кичүе (җир асты һәм җир өсте) буенча иң кыска ара буенча үлчәнә. Җәяүлеләр зонасы машина юллары белән кисешкәндә, ара иң якындагы җәяүлеләр кичүе буенча үлчәнә.

Тротуарлар, җәяүлеләр юллары, җәяүлеләр кичүе буйлап ара әлеге объектларның уртасыннан (үзәк линиядән) үлчәнә.

3. Әлеге тәртипнең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән объектларның бинасында (төзелмәсендә, корылмасында) килүчеләр өчен бердән артык керү урыны булганда, янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара һәрбер керү урыныннан билгеләнә.

4. Янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләгәндә, бинаның (төзелмәнең, корылманың) янгын, запас һәм башка керү урыннары исәпкә алынмый.

5. Тротуар дигәндә, җәяүлеләр хәрәкәт итү өчен билгеләнгән һәм машина яки велосипед юлына тоташа торган яисә алардан газон белән бүленгән юл элементы аңлашыла.

6. Җәяүлеләр юлы дигәндә, җәяүлеләр хәрәкәт итү өчен җиһазландырылган яки яраклаштырылган җир полосасы яисә ясалма корылма өслеге аңлашыла.

7. Җәяүлеләр кичүе дигәндә, тамга белән билгеләнгән машина юлы, трамвай юллары участогы аңлашыла.

8. Җәяүлеләр зонасы дигәндә, җәяүлеләр өчен билгеләнгән, башы һәм ахыры махсус билгеләр белән билгеләнгән территория аңлашыла.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина